# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклауга юнәлдерелгән чаралар һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында" 1998 елның 18 июнендәге 1659 номерлы Татарстан Республикасы Законының 43 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (I өлеш); 2003, № 5; 2004, № 3 (I өлеш); 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 12 (II өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш), № 12 (II өлеш), түбәндәге эчтәлекле җиденче өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

"Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклау максатларында һәм федераль законнар нигезендә наркотик чаралардан, психотроп матдәләрдән һәм аларның прекурсорларыннан тыш башка фармакологик актив матдәләре булган дару препаратлары булып торучы, аз микъдарда наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары булган препаратларга (алга таба – аз микъдарда наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары булган дару препаратлары) карата аларны язып бирүгә, җибәрүгә, исәпкә алуга куела торган таләпләр билгеләнергә мөмкин. Аз микъдарда наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары булган дару препаратлары исемлеге, шулай ук аларга карата кулланыла торган контроль чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.".

**2 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш),

№ 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2011, 22 июнь, 6 август, 18 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 3.12 статья өстәргә:

"3.12 статья. **Аз микъдарда наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары булган дару препаратларын язып бирүгә, җибәрүгә һәм исәпкә алуга куела торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрне бозу**

Аз микъдарда наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары булган дару препаратларын язып бирүгә, җибәрүгә һәм исәпкә алуга куела торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрне бозган өчен –

вазыйфаи затларга – илле мең сум күләмендә; юридик затларга бер миллион сум күләмендә административ штраф салына.";

2) 7.1 статьяда "3.7 – 3.10," саннарыннан соң "3.12," саннарын өстәргә;

3) 8.1 статьяда:

а) икенче өлештә "3.11," саннарыннан соң "3.12," саннарын өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа тугызынчы өлеш өстәргә:

"Әлеге Кодексның шушы статьясындагы беренче һәм икенче өлешләрендә каралган очраклардан тыш, 3.12 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының вазыйфаи затлары төзергә хокуклы.";

в) тугызынчы – уникенче өлешләрне тиешенчә унынчы – унөченче өлешләр дип санарга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми кабул ителгән көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә һәм 2012 елның 1 июненә кадәр гамәлдә була.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 3 ноябре
№ 78-ТРЗ